КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 март г.Казань № 133

«Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү тәртибен раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021ел, 15 март, 133 нче
карары белән расланды

«Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары нигезендә эшләнде һәм «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага субсидия (алга таба – субсидия) бирү максатын, тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Субсидия «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирелә.

1.3. Субсидия турындагы мәгълүматлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

1.4. Субсидия алучы Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан, коммерциягә карамаган оешмаларның сайлап алу критерийларына һәм таләпләренә

туры килү-килмәвеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашуга тәкъдимнәр (заявкалар) (алга таба – заявка) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

1.5. Министрлык акча белән баш эш итүче булып тора, аңа бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелә.

1.6. Коммерциягә карамаган оешма түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра;

махсуслаштырылган оешма булып тора һәм «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торак шартларын яхшыртуга дәүләт ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ гражданнарның җыелма реестрын алып бара;

коммерциягә карамаган оешманың устав эшчәнлегендә төп төре булып төзелешне, шул исәптән торак йортлар, торак комплекслар, социаль, инженерлык инфраструктурасы объектлары төзелешен һәм төзекләндерүләрне инвестицияләү, төзелешне финанслау һәм аны тикшерүдә тоту; торак сатып алу, аны реализацияләү, шулай ук аны реконструкцияләү тора.

1.7. Чыгымнар юнәлеше булып «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тора.

## II. Субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Сайлап алуны үткәрү максатларында, Министрлык тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында карар кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://minstroy.tatarstan.ru/) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән ким булмаган сайлап алуны үткәрү срокларын (сайлап алуда катнашучыларның заявкалар бирү (кабул итү) башлану (тәмамлану) датасын һәм вакытын);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын һәм электрон почта адресын;

ирешү өчен әлеге Тәртипнең 3.8 пунктында каралган субсидия бирү нәтиҗәсен (алга таба – субсидия бирү нәтиҗәсе);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителәэ торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләрен (әлеге Тәртип нигезендә);

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану вакытын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – Килешү) куелырга тиешле имза кую вакытын;

сайлап алуда җиңүчене Килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында, сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасын.

Сайлап алуны үткәрү чорында сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләре, әгәр дә сорату Министрлыкка заявкалар бирү срогы тәмамлану датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча керсә, Министрлык тарафыннан сайлап алуда катнашучыларга Министрлыкка тиешле сорату кергән датадан биш эш көне эчендә электрон документ рәвешендә кергән соратуда күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә яки язма рәвештә кергән соратуда күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә бирелә.

2.2. Сайлап алуда катнашучы сайлап алу үткәрү турында белдерү урнаштырылган ай алдыннан килгән айның 1енә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән Татарстан Республикасының башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында акча йөкләмәләре буенча башка үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмый торган) бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү һәм аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат

ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булып тормау;

әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә субсидия бирү каралган елда Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау.

2.3. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар Министрлыкка аның тарафыннан билгеләгән форма буенча түбәндәге документлар белән заявка тапшыра:

гамәлгә кую документлары, шулай ук сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан имзасы һәм мөһере белән аларга барлык үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү турындагы документлар күчермәләре;

сайлап алуда катнашучының мөһере белән расланган юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан язу кәгазе күчермәсе;

«Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруны башкара торган махсуслаштырылган оешма тарафыннан сайлап алуда катнашучыны билгеләү хакындагы документның күчермәсе;

заявкалар кабул итү вакыты башланганга кадәр өч айдан да иртәрәк бирелмәгән сайлап алуда катнашучы турындагы мәгълүматлар белән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә күчермәсе;

салым органы тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерү игълан ителгән айга кадәр килгән айның беренче көне хәленә карата Россия Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процент-лар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турында белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имзаланган, мөһер сугылган, субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән Татарстан Республикасының башка хокукый актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында акча йөкләмәләре буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау турында белешмә кәгазе;

сайлап алучының әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә субсидия бирү каралган елда Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавын

раслый торган, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имзаланган белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имзаланган белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының Министрлык тарафыннан бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка һәм сайлап алу белән бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгы.

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан үз инициативасы белән әлеге пунктның бишенче һәм алтынчы абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар бер папка (том) итеп тегелгән, һәр битенә номерлар сугылган, сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең үз имзасы белән имзаланган һәм мөһер белән расланган булырга тиеш.

Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр (сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең үз имзасы белән расланган һәм мөһер белән расланган төзәтмәләрдән тыш) рөхсәт ителми.

Министрлыкка заявкалар кабул итү вакыты башланганга кадәр яки заявкалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң (шул исәптән почта элемтәсе оешмалары аша) килгән заявкалар теркәлми, карап тикшерелми, бу турыда заявка кергән көннән 10 эш көне эчендә Министрлык электрон почта аша сайлап алуда катнашучыга хәбәр итә һәм аңа заявканы почта элемтәсе оешмасы аша кире кайтара.

2.4. Заявкалар кабул итү вакыты тәмамланганга кадәр сайлап алуда катнашучы ирекле рәвештә язылган гариза буенча заявканы (шул исәптән заявкага үзгәрешләр кертү һәм яңа заявка бирү максаты белән) кире алырга хокуклы.

Әгәр дә заявкалар бирү срогы чыкканга кадәр заявкага үзгәреш кертү сайлап алуда катнашучы тарафыннан яңа заявка бирү юлы белән гамәлгә ашырылса яки аны кире алу турындагы хәбәрнамә  Министрлык тарафыннан алынса, заявкага үзгәреш кертү яки аны кире алу турындагы хәбәрнамә гамәлдә дип санала.

Министрлык сайлап алуда катнашучыларның заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срокта бирелгән заявканы кабул итә һәм заявканы кергән көнендә субсидияләр алу өчен заявкаларны теркәү журналында терки, анда заявканың керү датасын һәм вакытын һәм заявкага тәртип буенча бирелгән теркәү номерын күрсәтә һәм сайлап алуда катнашучыга, заявканы алу датасын һәм бирелгән теркәү номерын күрсәтеп, аны алу турында кәгазь бирә.

Заявка Министрлыкка почта элемтәсе оешмалары аша кергәндә, ул субсидия алу өчен заявкаларны теркәү журналында теркәлә. Бу очракта заявканы алу турында кәгазь язылмый, субсидия алу өчен заявкаларны теркәү журналында теркәү датасы

итеп почта элемтәсе оешмасына почта юлламасының штемпеле белән расланган почта юлламасын тапшыру датасы күрсәтелә.

2.6. Сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын карап тикшерү максатларында, Министрлык тарафыннан заявкаларны карап тикшерү комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

Комиссия Министрлык хезмәткәрләре һәм Министрлык каршындагы иҗтимагый советлар вәкилләре арасыннан төзелә.

Комиссия заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән соң килә торган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә:

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканы һәм аңа теркәлгән документларны, аларның керү чиратын саклап, шулай ук сайлап алуда катнашу-чының әлеге Тәртипнең 1.6, 2.2 һәм 2.3 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә;

заявканың әлеге Тәртипнең таләпләренә туры килүен тану турында яки заявканы алмау турында карар кабул итә, ул беркетмә белән рәсмиләштерелә.

2.7. Сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын аларны карап тикшерү һәм бәяләү стадиясендә кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 1.6 һәм 2.2 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы биргән заявканың һәм документларның сайлап алу турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы биргән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлауда катнашучы тарафыннан заявканы кабул итү срогы башланганга кадәр яки заявкалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки ) вакыттан соң (шул исәптән почта элемтәсе оешмасы аша) заявка бирү.

Комиссия заявканы кабул итмәү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә сайлап алуда катнашучыга, заявканы кабул итмәү сәбәбен күрсәтеп, кабул ителгән карар турында электрон почта аша хәбәрнамә җибәрә.

Сайлап алучы тарафыннан бирелгән заявка һәм аңа теркәлгән документлар әлеге Тәртипнең 1.6, 2.2 һәм 2.3 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килгән очракта, Комиссия заявкаларны карап тикшерү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә, заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашучының берсенә карата сайлап алуны үтү турында карар кабул итә.

2.8. Министрлык, Комиссия тарафыннан карар кабул ителгән көннән соң 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итмәү сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый гаризалар туры килми торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

Килешү төзелә торган сайлап алуда катнашучының исеме һәм бирелә торган субсидиянең күләме (алга таба – субсидия алучы).

## III. Субсидия бирү тәртибе

3.1. Субсидия алучы бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алуны үткәрү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән 5 эш көне эчендә Министрлыкка аның тарафыннан билгеләнгән форма буенча Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә ризалыгын үз эченә алган субсидия бирү турында гариза кертә.

3.2. Министрлык субсидия бирү турындагы гаризаны кабул итә һәм, субсидия бирү турындагы гаризаның керү датасын күрсәтеп, субсидия бирү турындагы гаризаны кергән көнендә субсидияләр бирү турындагы гаризаларны исәпкә алу журналында терки һәм субсидия алучыга, гаризаны алу датасын һәм бирелгән теркәү номерын күрсәтеп, субсидия бирү турындагы гаризаны алу хакында расписка бирә. Субсидия бирү турындагы гариза почта элемтәсе оешмасы аша кергәндә, ул кергән көнне, почта юлламасының Министрлыкка килү датасын һәм вакытын күрсәтеп, субсидияләр бирү турындагы гаризаларны исәпкә алу журналында теркәлә.

3.3. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү турында гариза бирү вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә аны карап тикшерә һәм субсидия алучыга субсидия бирү яки бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

3.4. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Тәртиптә каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнән торган өч көн эчендә субсидия алучыга, баш тартуның нигезләрен күрсәтеп, хәбәрнамә җибәрә.

3.5. Субсидия Министрлык һәм субсидия алучы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча төзелә торган Килешү нигезендә бирелә.

3.6. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре, субсидияне күчерү тәртибе һәм сроклары;

субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында һәм өстәмә хисаплылык (кирәк булганда) бирү сроклары һәм формалары;

агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешен кире кайтару очраклары;

субсидия алучының һәм Килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булып торган затларның Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә ризалыгы;

субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртип һәм төзелә торган Килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр;

субсидия алучы тарафыннан, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан алынган субсидияләр исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю турында шарт;

бюджет акчасын алучы буларак Министрлыкка әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән, Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешеп булмаганда Килешүне өзү турында шарт.

Килешү Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә төзелә.

Кирәк булуга карап, Министрлык һәм субсидия алучы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган формалар буенча Килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән Килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

3.7. Субсидия ай саен Министрлык тарафыннан ул раслаган форма буенча заявка нигезендә заявка кергәннән соң биш эш көне эчендә субсидия алучының кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына күчерелә.

3.8. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе – субсидия бирелгән елның 31 декабре хәленә карата социаль ипотека системасында торак хокукын гамәлгә ашыручы, бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтүдән файдаланган 3 000 (өч мең) гаилә.

3.9 Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = К \times Р,$$

монда:

К – «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торак хокукын тормышка ашыручы, бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда түләүләр башкарыла торган гаиләләрнең 3 000 (өч мең) күләмендә кабул ителә һәм планлаштырыла торган саны;

Р – «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы

Законы нигезендә торак хокукын тормышка ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда 200,0 мең сум күләмендә кабул ителә торган түләүләр суммасы.

## IV. Хисаплылыкка карата таләпләр

4.1. Субсидия алучы Министрлыкка, субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Килешүнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формасына теркәлә торган формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплылык бирә.

4.2. Субсидия алучы бирә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидияләрдән максатчан файдаланылмау өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

## V. Тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруга карата таләпләр

5.1. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары субсидия алучының Россия Федерациясе законнары нигезендә субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

5.2. Субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

5.3. Субсидия аны алучы тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылган һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплылык һәм өстәмә хисаплылык (ул Килешүдә билгеләнгән очракта) бирелмәгән очракларда, тулы күләмдә;

субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешелмәгән очракта, субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсеннән тайпылуга пропорциональ рәвештә билгеләнә торган күләмдә.

5.4. Субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 5.2 һәм 5.3 пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару сроклары бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

5.5. Бирелә торган субсидияләрне максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

_______________________________